Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге Советы

Кибәч авыл җирлеге башлыгы
# КАРАРЫ

2 июнь, 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге башлыгының «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 20 апрелендәге 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә карар бирәм:

1. «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турындагы Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 20 апрелендәге 1 номерлы карары (Башлыкның 2023 елның 08 сентябрендәге 2 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов